# «Советлар Союзы Геройлары –татарлар» гимназия музее






Автор: Мөхетдинова Азалия Ленар кызы
Җитәкче: Гатауллин Радик Равил улы

Тарихны, киләчәктә яңа хаталар ясамас өчен, өйрәнәләр. Үткәннәрне белү, ата-бабаларның мирасын истә тоту һәм шул ук вакытта булган белемнәрне дә камилләштерү – мәгарифнең төп максатлары. Шулай итеп, бу принциплар укыту процессында да чагылырга да тиеш. Һичшиксез, шуңа күрә безнең гимназиядә, югарыда әйтелгәннәрне аңлап, Бөек Ватан сугышында катнашкан татарлар- Советлар Союзы Геройларына багышланган музей ачалар.

Музей, башка тарихи-мәдәни комплекслар сыман, барлык әйберләрне үз күзләрең белән күрергә һәм узган вакыт аша узарга ярдәм итә. Әлбәттә, музей тарих дәресләрендә һәм укудан тыш чараларда да әһәмиятле роль уйный. Ул яшьләрдә патриотик хисләр формалаштыруда мөһим инструмент булып хезмәт итә, тарихи хәтерне саклап калуга гына түгел, гражданлык җаваплылыгын тәрбияләүгә дә ярдәм итә. Укучылар, монда кергәч, үзләрен бүтән дөньяда сыман хис итәләр.

Зур булмаган мәйданда бай, кыйммәтле экспонатлар, портретлар, биографияләр яши.

**Проектның максаты:**

1. Музей эксонатларын өйрәнү, шәхесләрненң биографияләре белән танышу
2. Музейны укучылар, укытучылар эшчәнлегендә , тәрбия өлкәсендә актив бер юнәлеш итеп алу








# Музей тарихы

Гимназия музее 2002 елда, Җиңү салюты яңгырап, 57 ел узгач оештырыла. Дистә еллардан соң  бу дәһшәтле сугыш турында нинди яңалыклар тупларга мөмкин була соң? Татар гимназиясендә Бөек Ватан сугышы геройлары булган татар солдатларының батырлыгына багышланган музей төзергә карар кылына. Музей булдыруның идея илһамчысы – халык мәгарифе отличнигы, тарих укытучысы Хөсәенов Александр Галинур улы. Иң элек аның әтисе- Бөек Ватан сугышында катнашкан батыр солдат- татар каһарманнарының эзен саклап калу теләге белән яшәгән. Гимназия ачылганнан Александр атасының хыялын бу бинада тормышка ашырырга сүз бирә.





Мәктәп музеен булдыру һәм үстерү - күп кырлы процесс, ул зур тырышлык, вакыт һәм төрле якларның катнашуын таләп итә. Аны барлыкка китерү өчен дөрес, ышанычлы чыганаклардан табылган мәгълүмат кына җитми – эстетик ягы да бик мөһим. Гимназиябездә озак еллар буе рәссам булып эшләүче  Сафина Фәридә апа шушы экспонатларга “җан өрә”, иң кыйммәтле ядкарьләрне  күз карасыдай кадерләп саклый.   Аның тырышлыгы белән музей өч тапкыр реконструкцияләнә һәм хәзер дә камилләшүдән туктамый. Периметр буйлап килгән, стендларда, һәр мәгълүмати җәдвалда, экспонатларны урнаштыруда, гомумән әйткәндә, һәр почмакта аның үз хезмәтенә карата булган  җылы мәхәббәте күренә.

Музейның үзенчәлеге шунда ки, биредә барлык Бөек Ватан сугышында катнашучы татарлар – Советлар Союзы Геройлары. Алар турында материал шәһәрдән генә түгел, республика буйлап җыела. Күп кенә мәгълүмат гимназия тарих укытучылары, Яшел Үзән шәһәре эзтабарлары тарафыннан туплана.








Йөзек кашы булып торган, өчпомаклы хатларны исә Ибраһимова Зәйтүнә Госман кызы бүләк итә. Алар, чынлап та, тарихның шаһитлары. Кайчандыр алар туган ил, газиз гаилә белән булган бердәнбер элемтә.

Ә менә Витриналарда урнашкан хәрби форманы Әдиятуллин Хәлит Әдиатулла улының хатыны бирә.

Музейдагы портретларны заказ буенча Яшел Үзән рәсем мәктәбе ясый. Ә скульптураларга килсәк – барысын да гимназияның иң якын кешеләреннән берсе, Шәрәфетдинов Вил абый ясаган. Ул иҗат иткән һәр бюстта шәхеснең холкы чагыла. Мәсәлән, Хөсәенов Александр Галинурович бюстын шушы гимназия хезмәт иткән Вил абый ясый.

«Татарстанда туганнар арысланнар кебек сугышалар". Бу безнең бабаларыбыз турында Советлар Союзы маршалы Иван Степанович Конев мактап әйткән сүзләр. Ә Генерал Владимир Александрович Шаталов түбәндәге фикерен әйтә: "Казан татарлары сугышта үзләрен батыр һәм кыю итеп күрсәттеләр. Алар аерылып тордылар. Бу аларның разведкага, автоматчикка – тормыш өчен иң куркыныч булган урынга баруларыннан күренә: безнең Ватаныбыз өчен гомерләрен дә кызганмаганмадылар». Музейда 164 герой турында бай мәгълүмат тупланган.

# Петр Михайлович Гаврилов -1957 елдан Советлар Сюзы Герое.




Фашистлар Брест крепостен бер көндә алырга диеп план төзиләр. Тик совет офицеры Петр Михайлович Гаврилов аларның планнарын тар- мар итә һәм 32 көн буе оборонада тора. Армиянең төп көчләре кичә җәйге лагерьларга урнаштырылган иде, крепостьта штаблар һәм берничә дежур рота гына калды. Җәһәннәм бомбалары һәм атышлардан исән калган крепость солдатларының төрле төркемнәреннән майор Гаврилов 400ләп исән калган сугышчыны җыя ала. Кулларында ике зенит орудиесе, берничә 45 мм пушка һәм дүрт көпшәле зенит пулеметы булган Гаврилов сугышчылары Брест крепостен яулап алырга теләгән фашистларга каты каршылык күрсәтәләр. Майор Гаврилов бер ялгызы кала, ул 23 июльгә кадәр төннәрен гитлерчыларны кыруын дәвам итә , тик яраланып, хәлсезләнә, аңын жуя һәм әсирлеккә төшә. Шаккаткан немецлар офицер формасындагы киенгән тере сөяккә хөрмәт һәм курку белән карыйлар. Соңрак шаһитлар сөйләгәнчә, үлем хәленә житкән, хәтта су да йота да алмаган майор, әсирлеккә төшәр алдыннан бер сәгать кала да дошман атакасына каршы торган. гитлерчылар тарафыннан ышана алмастай гамәл кылына: алар Гавриловны атмыйлар!

1941 елның 23 июлендә Гаврилов әсирлеккә төшә. Сугыш беткәнче, ул концлагерьларда тотыла, ә 1945 елда Совет солдатлары тарафыннан азат ителә. 1957 елда Петр Гавриловка Советлар Сюзы Герое исеме бирелә.

# Гвардия полковнигы Барый Йосыпов-атаклы «Катюша» реактив минометларның беренче дивизионы командиры







Мәскәү өчен барган сугышларның хәлиткеч чорында Ватан Бари Абудллович Йосыповка ул вакыттагы иң серле Яңа коралны – атаклы «Катюша» реактив минометларның беренче дивизионын ышанып тапшыра. 1942 елның гыйнварында Йосыпов җитәкчелегендәге «Катюша» оператив группасы төньяк-көнбатыш фронтка күчерелә. Кышкы көннәрнең берсендә буран куба, «Катюша» дивизионы да көрт эчендә кала. Полковник Йосыпов оборонага җитәкчелек итә. Сугыш барышында ул үзе фашист танклары белән сугышка чыга һәм аларның чылбыры астына граната ыргыта. Госпитальдә Армиянең Баш сәяси идарәсе башлыгы Александр Сергеевич Щербаков Барый Йосыповка башкаланы саклауда күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен Ленин орденын шәхсән үзе тапшыра.

# Герой-артиллерист Зәки Шәймәрданов







Зәки Шәймәрдановның сугышчан юлы Сталинград өчен сугыштан башлана. Беренче көннәрдән үк ул Ватанга биргән антын намус белән үти. Яшь артиллерист-наводчик Зәки Шәймәрдановның сугышчан осталыгы бик тиз үсә. Сталинград өчен барган сугышларда ул үз орудиесыннан атылган снаряд белән дошман танкларына ут төртә. Бу сугышта ул салкын канлылык, үз көченә ышаныч, ныклык күрсәтә. Гитлерчылар көн саен берничәшәр атака ясый, ләкин һәрвакыт безнең артиллерия уты аларның атакасын кире кайтара.

Сугышта ул тиңдәшсез батырлык күрсәтә. Дошман, сугыш кырында яндырылган тагын дүрт танк калдырып, чигенергә мәҗбүр була. Аның хәрби исәбендә җимерелгән егерме дүрт танк, унсигез бронетранспортер, егерме бер орудие һәм кырылган берничә йөз гитлерчы. Шушы батырлыклары өчен Зәки Шәймәрдановка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

# Бүгенге көн батырлары

Бүгенге көннәрдә дә татар егетләре үз ватанпәрвәрлекләрен күрсәтүдән туктамыйлар.

Марат Радик улы Әхмәтшин 1980 елның 27 июнендә Камчатка өлкәсенең Елизово шәһәрендә нәселле хәрбиләр гаиләсендә туа. Маратның бабасы хәрби диңгезче, әтисе хәрби очучы була. Россия Федерациясе Президентының 2016 елның 23 июнендәге Указы нигезендә капитан Әхмәтшинга «Махсус бурычларны үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен» Россия Федерациясе Герое исеме бирелә. 31 августта Казан Кремлендә геройның гаиләсенә «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Ә бу егет батырлыгы турында бөтен гимназиябез горурланып сөйли. 2014 нче елда гимназияне тәмамлаган Гафур Фәрит улы Шакирҗанов. 2018 нче елда ул Казан танк училищесын тәмамлый. 2022 нче елның 13 мартында 26 яшьлек Украина территориясендә Буйнакск шәһәре 136 нчы мотоукчылар бригадасының өлкән лейтенанты, танк батальоны взводы командиры Шакирҗанов Гафур Фәрит улы һәлак була. Үлгәннән соң Батырлык ордены белән бүләкләнә.




(Марат Радик улы Әхмәтшин)




(Гафур Фәрит улы Шакирҗанов)

Безнең алдыбызда үсеп килүче буынга ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү бурычы тора. Гимназия музее моның өчен-иң отышлы җирлек: җанлы экскурсияләр моның ачык мисалы.  Иң сөендергеч факт: музей башлангыч, урта һәм югары сыйныфларга да бик файдалы.

Шул ук вакытта музей – гимназиянең визит карточкасы да булып тора. Килгән кунаклар аның эчтәлеге белән соклана. Күптән түгел, музейда  март аенда ТР рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте» Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең Татарстандагы төбәк бүлеге җитәкчесе Тимур Җәүдәт улы Сөйләйманов та булды. Ул да музейга бик югары бәя бирде.

Ахырдан, экспозицияне яңартуны, укучыларны актив җәлеп итүне, башка учреждениеләр белән хезмәттәшлекне һәм музей ресурсларын белем бирү процессына интеграцияләүне үз эченә алган сугышчан дан мәктәп музеен үстерүгә комплекслы якын килү аның нәтиҗәлелеген сизелерлек күтәрергә мөмкинлек бирәчәк. Бары тик шулай гына музей тарихи хәтерне саклау һәм яшь буында гражданлык позициясен формалаштыру буенча үзенең мөһим миссиясен үти ала. Бу тикшеренү раслаганча, хәрби дан мәктәп музее - тарихи артефактларны саклау гына түгел, ә белем бирү процессының актив катнашучысы да, ул укучыларда патриотик хисләр һәм үз иле тарихына хөрмәт формалаштыруга ярдәм итә.

